ЯКШӘМБЕ
7
ФЕВРАЛЬ
1943 ел.
№ 31 (6753)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

Совхозлар эшендә кискен борылыш ясалырга тиеш

Бөек ватан сугышы колхозлардан һәм совхозлардан тагын да энергиялерәк эшләүне таләп итте. Колхозчылар һәм совхоз эшчеләре моны бик яхшы аңладылар һәм берничә кат арттырылган энергия белән эшли башладылар. Менә Москва өлкәсе совхозлары. Алар арасында вакытлыча оккупацияләнүгә очраган совхозлар да бар иде. Шуңа да карамастн, алар үзләренең ватан каршындагы бурычларын намус белән үтәделәр, дәүләт йөкләмәләрен үтәү өстенә Кызыл Армия фондына да йөзләрчә центнер ашлык, ит, май, йон һәм тиреләр биреп, Кызыл Армиянең рәхмәтен алуга ирештеләр.

Татарстан АССР территориясендә дә күп кенә совхозлар бар. «Коминтерн» совхозын алыйк. Ул терлекчелек эшен көннән-көн яхшырта, илебез өчен терлекчелек продуктлары житештерүне көчәйтә бара. Югары иген уңышы алу буенча да узган ел матур гына күрсәткечләр бирде. Мәсәлән, тамыр азыкларының һәр гектарыннан 150—200 центнерга кадәр уңыш алды.

Ләкин Татарстан совхозлары арасында мондыйлар бик аз әле. Күп кенә совхозларыбыз хәзерге шартлар таләп иткәнчә эшләмиләр әле. «Большевик», «Комсомолец», «Красный восток» һәм Вахитов исемендәге совхозларны күрсәтергә мөмкин. Алар гадәттән тыш начар эшлиләр. Хәрби уңыш өчен көрәшмиләр. Бу совхозларда терлекләрнең дә хәле яхшыдан түгел. Язгы чәчүгә әзерлек начар оештырылган. Чәчүлек орлык әзер түгел. Авыл хуҗалыгы инвентарена ремонт бик акрын бара. Кышкы агротехника чараларын үткәрү башланган гына әле. Дәүләт алдындагы йөкләмәләр бик акрын үтәлә.

Кайбер совхозларның житәкчеләре эштәге кимчелекләргә сугыш вакыты кыенлыклары, машиналар, ат көчләре һәм кадрлар житешмәү сәбәп булып тора дип күрсәтергә тырышалар. Ләкин бу аларның булдыксыз һәм җебегән булуларын гына күрсәтә. Совхозлардагы мөмкинлекләр колхозларга караганда да зуррак. Тракторлар, комбайннар һәм башка авыл хуҗалыгы инвентарьлары тулысы белән житәрлек. Ат көчләре дә шулай ук күп.

Совхозлардагы кимчелекләрнең төп сәбәбен, барыннан да элек, хезмәт дөрес оештырылмаудан эзләргә кирәк. Татарстанның кайбер совхозларында шушы көнгә кадәр әле эштә звено ситемасы юк. Трактор бригадалары төзеп, эшне график нигезендә алып баруга аз игътибар ителә. Тракторлардан һәм комбайннардан тиешенчә файдаланмыйлар. Кадрларның квалификацияләрен күтәрүгә, алар арасында булган инициативага, эшне рационаллаштыру тәкъдимнәренә әһәмият бирелми.

Тамыр азык чәчү, алардан мул уңыш алу, күп еллык үләннәр үстерү ит һәм сөтчелек совхозларының экономик базасын ныгытуда гаять зур урын тота. Шулай да бу эшкә әһәмият бирелми. Мәсәлән, тамыр азыкларны яхшылап тәрбияләмәү аркасында «Большевик», «Комсомолец» һәм Чирмешән совхозларында узган ел уңыш бик түбән булды. Чөнки бу совхозларда үсемлекләрнең рәт araларын эшкәртү, чүп үләннәрен утау һәм авыл хуҗалыгы корткычларына каршы көрәш чаралары үткәрелмәде. Бу совхоз житәкчеләре күп еллык үлән үстерүне артык эш дип исәпләгәннәр. Мәсәлән, Актагыш совхозы үткән елны 1.000 гектар урынына бары 160 гектар гына үлән чәчкән.

Менә шушыларның нәтиҗәсе буларак, Татарстанның күп кенә совхозлары 1942 нче елны дәүләт алдындагы йөкләмәләрне үтәп житкермәделәр. Бу, фронтның таләбен, бөек ватаныбызның таләбен үтәмәү дигән сүз. Моның шулай икәнен совхоз җитәкчеләре аңларга тиешләр.

Тагын шуны әйтергә кирәк: ВКП(б) ның кайбер райкомнары совхозлар эшенә бик аз игътибар бирәләр, совхозларның партия оешмаларыннан һәм комсомол оешмаларыннан эштә җаваплылыкны таләп итмиләр. Бу кимчелекне тиз бетерергә, совхозларга җитәкчелекне кискен төстә яхшыртырга һәм яхшы нәтиҗәләргә ирешергә кирәк—партия оешмаларының, совхоз политбүлекләренең иң мөһим бурычларыннан берсе әнә шул.

Соңгы сәгатьтә

Безнең гаскәрләр Лисичанск, Барвенково, Балаклея, Батайск, Ейск шәһәрләрен алдылар

1) 6 нчы февральдә УКРАИНАДА безнең гаскәрләр бик каты сугышлар нәтиҗәсендә ЛИСИЧАНСК шәһәрен һәм тимер юл станциясен, БАРВЕНКОВО шәһәрен һәм тимер юл станциясен, БАЛАКЛЕЯ шәһәрен һәм тимер юл станциясен алдылар.

2) РОСТОВ-ДОННАН көньяктарак безнең гаскәрләр каты сугыштан соң БАТАЙСК шәһәрен һәм тимер юл узелын алдылар.

3) Безнең гаскәрләр, һөҗүмне уңышлы җәелдерүне дәвам иттереп, АЗОВ диңгезе ярына барып чыктылар һәм ЕЙСК шәһәрен һәм портын алдылар.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

6 НЧЫ ФЕВРАЛЬГӘ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

6 нчы февральгә каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Ростов-Доннан көньяктарак безнең гаскәрләр дошманның берничә терәк пунктын алдылар. Моторлаштырылган Н-че часть, омтылышлы ударлар белән, тимер юл станциясенә бәреп керде һәм немецларның танклар, автомашиналар, сугыш припаслары һәм снаряжение төялгән бер хәрби эшелонын кулга төшерде. Икенче бер участокта безнең подразделениеләр халык яши торган ике зур пунктны алдылар. Ике рота немец пехотасы юк ителде. Пленныйлар алынды һәм трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Красный Лиман районында безнең гаскәрләр һөҗүм операцияләре алып бардылар. Халык яши торган бер зур пункт өчен булган сугышларда немецларның бер батальон пехотасы тар-мар ителде, 4 танк, 7 орудие, 4 миномет, 16 пулемет, 25 автомашина һәм башка төрле сугыш милекләре кулга төшерелде. 200 дән артык дошман солдатлары һәм офицерлары кырып ташланды. 115 немец плен алынды. Дошман тылында хәрәкәт итүче безнең отрядлар халык яши торган зур пунктларда немецларның өч гарнизонын кырдылар һәм дошманның ягулык һәм азык төялгән автоколоннасын кулга төшерделәр.

* * *

Курскидан көнчыгыштарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Н-че берләшмә частьлары халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар һәм 300 гә якын кешене плен алдылар. Старый Оскол шәһәрендә чолганып алынган дошман гарнизоны соңгы көннәрдә шәһәрдән котылып чыгу өчен берничә тапкыр бик каты контратакалар ясап карады. Безнең частьлар гитлерчыларның барлык атакаларын кире кайтардылар һәм аларны авыр югалтуларга дучар иттеләр. Кичә безнең частьлар дошманның чолганып алынган гарнизонын юк иттеләр һәм бер өлешен плен алдылар.

* * *

Витебск өлкәсендә хәрәкәт итүче партизаннарның бер отряды ике атна эчендә дошман гаскәрләре төялгән 2 эшелонны, кораллар һәм сугыш припаслары төялгән 3 составны юлдан чыгарганнар. Икенче бер отрядның бер группа партизаннары январь ахырында сугыш йөкләре төялгән бер эшелонны һәлак итүне оештырганнар. Паровоз һәм 20 вагон сафтан чыгарылган. Тимер юлның бу участогында хәрәкәт тукталган.

* * *

Немецларның 83 нче пехота дивизиясенең 277 нче полкының плен алынган командиры, Великие Луки шәһәренең элекке немецлар гарнизоны начальнигы, подполковник фон Засс болай диде: «Великие Луки шәһәрендә чолганып алынган немецлар гарнизоны бөтенләй юк ителде. Гарнизонның калдыклары кораллары ташладылар. Шәһәрдә сугыш припаслары һәм азык складлары бар иде, ләкин һөҗүм барышында руслар шәһәрне берничә өлешкә бүлделәр һәм алар арасында бернинди дә элемтә булмады. 83 нче дивизия командиры генерал Шерер, Гитлер исеменнән безгә һәр көнне бер үк приказны кабатлап тора иде: «Актык кеше калганчыга кадәр чигенмәгез». Шуның белән бергә, Шерер, гарнизонга ярдәмгә зур көчләр килә, дип белдерде. Ләкин ярдәм һаман да килмәде. Рухлары төшкән солдатларның күңелен күтәрергә теләп, Шерер гарнизонның барлык солдатларын икенче дәрәҗәдәге тимер тәреләр белән, ә унтер-офицерларны беренче дәрәҗәдәге тимер тәреләр белән бүләкләргә приказ бирде. Минем үземә самолет белән рыцарь тәресе китерделәр. Ләкин бу бүләкләр дәртләндермәделәр. Киресенчә, солдатлар үзләренең тормышларын мәгънәсезгә корбан итәргә мәҗбүр булуларына чиктән тыш ачулары чыкты. Үзебезнең һәлакәткә дучар булганлыгыбызга ышанганнан соң мин, солдатларның басымы астында, үз штабым белән бергә пленга бирелдем. Минем белән бергә 56 офицер бирелде».

* * *

Югославиянең бер группа партизаннары Загреб якынындагы Буяновида нефть промыслоларына үтеп кергәннәр һәм немец сакчыларын үтереп бетергәннәр. Партизаннар, инженерлар ярдәме белән, промышленность корылмаларын шартлаткannar һәм нефть промыслоларының барлык җиһазларын юк иткәннәр.

Артиллерия маршалы иптәш Н. Н. ВОРОНОВКА, генерал-полковник иптәш К. К. РОКОССОВСКИЙГА, генерал-лейтенант иптәш Ф. И. ТОЛБУХИНГА беренче дәрәҗә СУВОРОВ ордены һәм генерал-лейтенант иптәш М. С. ГРОМАДИНГА беренче дәрәҗә КУТУЗОВ ордены тапшыру

Шушы елның 5 нче февралендә Кремльдә СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш **М. И. Калинин** артиллерия маршалы иптәш **Н. Н. Вороновка**, генерал-полковник иптәш **К. К. Рокоссовскийга**, генерал-лейтенант иптәш **Ф. И. Толбухинга** беренче дәрәҗә **Суворов** орденнары һәм генерал-лейтенант иптәш **М. С. Громадинга** беренче дәрәҗә **Кутузов** ордены тапшырды.

Эштә булган ватан сугышы инвалидларына льготалар

СССР Халык Комиссарлары Советы предприятиеләрдә, учреждениеләрдә һәм колхозларда эшләүче ватан сугышы инвалидлары өчен күп кенә льготалар билгеләде. Предприятиеләрдә һәм учреждениеләрдә эшләүче ватан сугышы инвалидлары өчен, аларның хезмәт хакларының күпме булуына карамастан, ә колхозларда эшләүчеләр өчен аларның доходлары күпме булуга карамастан, пенсияләре саклана. Предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең җитәкчеләренә, врач-хезмәт эксперты комиссияләренең нәтиҗәләре булганда, инвалидларга чираттагы ялны бирергә рөхсәт ителә. Вакытлы рәвештә хезмәткә яраклылыгын югалткан ватан сугышы инвалидларына, аларның өзлексез эш стажлары күпме булуга карамастан, пособия түләнә.

(ТАСС).

АЗАТ ИТЕЛГӘН ВОРОНЕЖДА

ВОРОНЕЖ, 5 февраль. (ТАСС). Шәһәрдә немец оккупантлары тарафыннан җимерелгән хуҗалыкны аякка бастыру эшләре башланды. Якын көннәрдә электр энергиясе белән тәэмин итү эше юлга салыначак. Өлкәдәге күп кенә районнар белән телефон элемтәсе булдырылды. Өлкә газетасы «Коммуна» ның беренче бюллетене чыкты. Шәһәр җанлана. Немец ерткычлардан качып якын-тирәдәге авылларда торган кешеләр шәһәргә торган саен күбрәк һәм күбрәк кайталар.

ХРОНИКА

— РСФСР Верховный Советы Президиумы иптәш М. Х. Третьяковны РСФСР ның төзү материаллары промышленносте халык комиссары итеп билгеләде.

— РСФСР Верховный Советы Президиумы иптәш Н. И. Васильевны РСФСР ның Орлыкчылык һәм Терлекчелек Совхозлары халык комиссары итеп билгеләде.

— РСФСР Верховный Советы Президиумы иптәш Д. А. Кривошеинны, эшен башкара алмаган өчен, РСФСР ның Орлыкчылык һәм Терлекчелек Совхозлары Халык Комиссары хезмәтләреннән азат итте.

Германиянең 6 нчы армиясенең бетүе

Подполковник А. ЕРУСАЛИМСКИЙ.

Германиянең 6 нчы армиясенең чолганып алынганлыгын бөтен дөнья белде. Тик немецлар пропагандасы гына бу турыда бер сүз дә дәшмәде. Ул, Кызыл Армиянең 6 нчы армияне чолгап алуны тәмамлаганлыгын һәм аны юк итү өчен уңышлы рәвештә сугыш алып баруын бик тырышып яшерде. 25 нче январьда немецлар радиосы: «Безнең солдатлар кайбер урыннарда чигенсәләр дә, яңадан корылып һәм үзләренең материаль көчләрен арттырып яңа һөҗүмгә бару өчен генә чигенәләр»,—дип мактанып белдергән иде. Ләкин безне капчыкта яшереп булмый. Шул ук көнне, берничә сәгать үткәч, немецларның радио тапшыруларында бер дә көтелмәгән яңа сүзләр ишетелә. Алар болай диләр: «Сталинград районында хәл шактый киеренкеләште... Дошман безнең фронт линиясен өзеп ташлый алды... Аның һөҗүме алдыннан чын мәгънәсе белән, гадәттән тыш көчле ут давылы булды, шуннан соң аның танклары безнең гренадерларыбызның траншеялары өстеннән шаулап үттеләр... Сталинград әйләнәсендә боҗра һаман кысыла барды». Ләкин менә 1 нче февральдә Германиянең информация бюросы «Сталинградта бетү турында хәбәр» тапшырды. Ул «армиянең югалганлыгын» икърар итәргә һәм шулай итеп «хәрби уңышсызлык бик җитди» икәнлекне аеруча әйтеп үтәргә мәҗбүр булды. Аннан соң Геббельс ведомствосы искиткеч тарихи яңалык ача. Ул немецларның Сталинград янындагы җиңелүләрен сугышлар тарихындагы иң зур җиңелүләр белән тиңләштерә һәм соңыннан бу җиңелүләр—җиңүләр иде дип исбат итәргә маташа.

Мәгълүм ки, үткән заманнарда рус халкы немец басып алучыларны берничә тапкырлар кыйнады инде. Мәсәлән, Тефтон рыцарьлары Ганненберг янындагы сугышта бик каты җиңелделәр. Ләкин, Германия информация бюросының 1 нче февральдә биргән хәбәренә караганда, немец халкы Танненберг белән мактана икән. Рус армиясе Кунерсдорф янында Фридрих II нчене тар-мар иткән иде, ләкин немецлар моның белән дә горурланырга тиешләр икән. Ниһаять, Германия информация бюросы «Наполеонның иң бөек эше, хәрби тарихчылар биргән бәягә караганда, Аустерлиц булмаган, бәлки Москвадан чигенгән чакта Березина елгасы аркылы кичүе булган» дип саный. Россиядә Наполеонның җиңелүе һәм аның Березина аркылы качуы—ул аның җиңүе иде дип кайсы «хәрби тарихчы» исбат итә ала,—бусы инде Геббельсның сере. Ләкин чагыштыруны тагын да дәвам иттерсәң, Германиянең 6 нчы армиясенең хәле Москвадан чигенгән Наполеон гаскәрләре хәленә караганда шактый начаррак булып чыга: бу армия китә алмады, чолганып алынды һәм хәзер бөтенләй юк ителде. Әгәр дә Геббельс ведомствосы Сталинград янында 6 нчы армиянең җиңелүен гүяки җиңү дип күрсәтергә әле һаман да маташа икән, монда шуны әйтергә мөмкин: тагын шундый берничә «җиңү» булса кешелек дөньясы гитлерчылар урдасыннан азат ителәчәк.

Сталинград районында немец гаскәрләренең нинди булса да очраклы бер группировкасы юк ителмәде, бәлки Германиянең кораллы көчләренең каймагы юк ителде, Европа илләре буйлап җиңү юлы үткән һәм немецларның иң эре генералларыннан берсенең җитәкчелегендә булган армия юк ителде.

Гитлер үзенең 6 нчы армиясе белән, аның гаять зур удар көче белән, аның солдатлары һәм офицерлары белән мактана иде. 6 нчы армиянең кадровый дивизияләре бөтенләй диярлек саф канлы арийаселе әтләреннән генә—Бранденбургта, Дрезденда, Баден-Баденда төзелгәннәр иде. Аның кайбер частьлары, мәсәлән, 79 нчы пехота дивизиясе 1939 нчы елның августында төзелеп, бөтенләй диярлек 22 дән 28 гә кадәр булган яшьләрдән генә,—фашизм демагогиясе белән аздырылган яшьләрдән тора иде. Күп солдатлар актык чиккә кадәр барып җиткән гитлерчылар иде. Пленныйларның әйтүенчә, кайбер частьларда һәрбер 5 солдаттан кимендә бер кеше нацистлар партиясе члены булган.

Гитлер 6 нчы армиягә аеруча җаваплы бурычлар тапшырды. Бу армия Көнбатышта беренче ударны ясарга тиеш булды. 1940 нчы елның 10 нчы маенда 6 нчы армия, Гитлер приказы буенча, хыянәтчел төстә, кечкенә Бельгия чигенә бәреп керде. Альберт каналы линиясендә Бельгия армиясенең каршылык күрсәтүен бастырып, 6 нчы армия, һәркайда да үлем һәм җимереклек таратып, ил буйлап давыл кебек үтте. Франциядәге кампания вакытында 6 нчы армия мәгълүм генерал-полковник Бок командалыгындагы «Б» группасы составына кергән иде. Ул чагында 6 нчы армиягә генерал-полковник Рейхенау җитәкчелек итә иде 6 нчы армиянең кадровый дивизияләре Көнбатыш Европаның күп илләреннән үттеләр. Брюссельгә һәм Парижга ясалган походтан соң алар Югославияне һәм Грецияне басып алуда катнаштылар. Алар сугышка кадәр үк инде үзләренең җиңел җиңүләренең исертә торган җимешләрен ашадылар: алар Чех-Словакияне оккупацияләүдә катнаштылар.

СССР га каршы башланган сугышның беренче көннәреннән үк Гитлер 6 нчы армияне Көнчыгышка җибәрде. 1942 нче елны Харьковтан Сталинградка кадәр, канын агыза-агыза үткән армия шул армия иде. Гитлер үзенең саташкан стратегик планының иң әһәмиятле өлешен тормышка ашыруны—Волга крепостен басып алуны әнә шул армиягә тапшырды. 6 нчы армиягә җитәкчелек итүгә ул ике бөтен дөнья сугышыннан зур практик тәҗрибә алган, шулай ук бу сугышларны хәзерләү тәҗрибәләре булган генералларны куйды. Немецлар группировкасын тар-мар итү буенча Сталин планын бик әйбәт һәм оста итеп тормышка ашырган совет генераллары каршына тәҗрибәле һәм куркынычлы дошманнар килеп баскан иде.

6 нчы армия командующие Фридрих Паулюс—Германия генералитетының характерлы вәкиле. Ул 53 яшендә. 33 ел буена армия сафларында булган. 1914—1918 нче елларда строй офицеры, ә ул сугыш бетеп килгәндә генеральный штаб офицеры булган. Ул чагында Паулюс көнбатыш фронттагы, Балкандагы һәм көньяк фронттагы операцияләрдә катнашкан. 1918 нче елны Германия армиясе җиңелгәннән соң да фон Паулюс отставкага чыкмаган. Ул озак вакытлар хәрби министрлыкта хезмәт иткән, ә соңыннан танк гаскәрләре идарәсенең штабы начальнигы булган. Шулай итеп, ул икенче бөтен дөнья сугышын әзерләүдә актив төстә катнашкан.

Гитлер Паулюсны бик җаваплы постка—генерал-фельдмаршал Рейхенау армиясенең штаб начальнигы итеп билгеләп, кинәт күтәреп җибәрде. Бу армия белән берлектә Паулюс 1939 нчы елның көзендә Польшаны таптап үтте, ә аннан соңгы елда Францияне тар-мар итүдә катнашты. Петэн тез чүккәннән соң озак та үтми, 1940 нчы елның сентябрендә Паулюс Германия армиясе генеральный штабының обер-квартирмейстеры итеп билгеләнде. Шулай итеп, Советлар Союзына Гитлер Германиясенең юлбасарларча һөҗүме башланганда инде Паулюс Гитлер генераллары арасында зур роль уйный башлады. 1942 нче елның январенда ул танк гаскәрләре генералы итеп билгеләнде, ә бер ел үткәч генерал-полковник дәрәҗәсе алды. Ләкин бу вакытта инде ул үзенең 6 нчы армиясе белән берлектә чолганып алынган иде. Сугышларның иң кызган чагында, Кызыл Армия үзенең тимер боҗрасын кысып, немецларның чолганып алынган группировкасына коточкыч ударлар ясаган вакытта Гитлер Паулюсны, рыцарьлык өчен бирелгән тимер тәре ордены өстенә, имән яфрагы белән бүләкләде. Аннан соң ул Паулюска генерал-фельдмаршал дәрәҗәсен бирде. Ләкин икенче көнне Паулюс үзенең штабы белән бергә пленга алынды.

3 нче февральдә әле Гитлер бу фактны юкка чыгарырга маташкан иде. Ул үзенең стратегия планнарының җимерелүен яшерергә омтылды һәм 6 нчы армиягә карата ясалма рәвештә мактау тудырды. Шул максат белән аның ставкасы сводкага махсус өстәмә белдерү игълан итте: «Репродукторлар, немец телендә сөйләп бирелергә тәкъдим итәләр, ләкин гаскәрләр барысы да торган урыннарында сугышуларын дәвам иттерәләр». Барысы дамы? Гитлер моның ялган икәнлеген һәм шуның өстенә тиз фаш ителә торган ялган икәнлеген белә иде. Аннан соң ул шулай да күңелсезлекләргә бирелеп: «совет гаскәрләренә тере килеш бирелүче немец солдатлары һәм союзниклар солдатлары бик аз булды«,—ди. Аның бик аз дигәне инде 91.000 нән артык солдат дигән сүз, ягъни—Паулюсның бөтен армиясенең өчтән бер өлеше дияргә мөмкин. Үзенең плен алынган 2.500 офицеры турында, 25 генералы турында һәм, ниһаять, генерал-фельдмаршал Паулюсның үзе турында Гитлер һаман да дәшми калуны артыграк күрә. Ләкин бөтен бер армиянең язмышы турында дәшми калу мөмкин түгел. Һәм шул ук көнне Гитлер ставкасы «фон Паулюсның үрнәк булырлык командалыгындагы 6 нчы армия җиңелде» дигән махсус белдерү игълан итте. Җиңелде! Бу—Гитлер өчен бөтенләй яңа сүз. 30 нчы январьда гына әле Гитлер, Геббельс аркылы, «капитуляция» дигән сүз немец теленнән бөтенләй сызып ташланды дип белдергән иде.

Фашистлар армияләренең иң көчлеләреннән берсен, сайланып алынган частьлардан төзелгән армияне, техника белән соң чиккә кадәр тәэмин ителгән һәм тәҗрибәле командованиесе булган армияне Кызыл Армия җиңде. Хәзер инде Гитлер: «6 нчы армиянең хәзер яңа дивизияләре оештырыла» дип немецларны юата. Ләкин боларның ясалма дивизияләр булачагын һәркем аңлый. Алар да шундый ук язмышка очраячаклар. Сталинград районында Германиянең 6 нчы армиясенең кадровый дивизияләре тар-мар ителгән кебек, алар да тар-мар ителерләр.

(«Красная Звезда», 5 фераль, 1943 ел).

Ленинград бүген. Тавыш тоткыч янында вахтада.

ТАСС фотохроникасы.

Батыр сугышчыларга җылы киемнәр

Красный бор районы колхозчылары данлыклы сугышчылар өчен җылы киемнәр җыю эшенә зур активлык белән катнашалар. Колхозчылар узган ел бик күп санда киез итекләр, йон, тун тегү өчен тиреләр, оекбашлар, бияләйләр һәм башка әйберләр җыеп, район складына тапшырдылар. Бу эш быел тагын да зуррак темплар белән дәвам итә. Күптән түгел ватан сугышы фронтыннан кайткан һәм хәзерге вакытта Ямурза авыл советы председателе булып эшләүче иптәш Нурмиев сугышчыларга җылы киемнәр җыю эшенә аеруча зур әһәмият бирә. Ул болай ди:

— Кызыл Армиянең җиңүен тагын да тизләтү өчен без бер нәрсәбезне дә кызганмыйбыз, фронтка ярдәм итәргә һәрвакыт хәзер торабыз. Фронттагы уңышлар безне яңа җиңүләргә рухландыра. Безнең колхоз дәүләткә ашлык тапшыру планын районда беренче булып үтәде. Танклар колоннасы һәм самолетлар эскадрильясы төзү фондына акча җыюда да без сынатмадык. Кызыл Армиягә җылы киемнәр җыю буенча да безнең авыл советы үзенең бурычын намус белән үтәде һәм үти.

Дөрестән дә Ямурза авыл советы җылы киемнәр җыю буенча районда алдынгылардан берсе. Авыл советы соңгы көннәрдә генә дә бер центнер йон, 136 данә тире, 83 пар йон бияләй һәм башка бик күп әйберләр җыеп тапшырды. Ямурза колхозчылары җылы киемнәр җыю буенча Пушкин исемендәге колхоз белән ярышалар. Пушкин колхозы членнары ямурзалырлардан калышмаска тырышалар. Алар да район складына кыска гына вакыт эчендә 64 данә тире, 110 килограмм йон, 60 пар бияләй җыйдылар.

Район буенча соңгы бер-ике ай эчендә сугышчыларга барлыгы 1.116 данә тире, 1.000 килограмм йон, 668 пар бияләй, 206 пар җылы оекбаш һәм 228 данә башка төрле җылы киемнәр әзерләнде.

Х. ХӘЙРИ.

МОСКВА ПРОФСОЮЗ АКТИВЫНЫҢ ҖЫЕЛЫШЫ

3 нче февральдә Союзлар йортының Колонналы залында Москва профсоюз активының җыелышы булды.

Җыелышны ВКП(б) ның Москва Шәһәр Комитеты секретаре иптәш Г. М. Попов ачты. Доклад ясау өчен сүз ВЦСПС секретаре иптәш Н. М. Шверникка бирелә. Иптәш Шверник болай ди:

— Москва профсоюз активы тарихи көннәрдә, Кызыл Армиянең бөек Сталин җитәкчелегендә уңышлы рәвештә алга барып, Совет җирен гитлерчы кабахәтләрдән чистарту көннәрендә җыелды. Дошманның Сталинград группировкасын тар-мар итү һәм юк итү тәмам булды. Сталинград янында булган сугыш Кызыл Армиянең тулы җиңүе белән төгәлләнде. Совет сугышчыларының гүзәл уңышлары дошманны тизрәк җиңү өчен тылны яңа хезмәт батырлыкларына рухландыралар. Бу көннәрдә фронт һәм тыл, бергәләшеп героик тырышлык күрсәтеп, Верховный Баш Командующийның приказын үтәүгә ирешәләр. Профсоюзларның да эше шушы максатка буйсындырылган булырга тиеш. Хәзер алар эшче һәм хезмәткәрләр турында, аларны азык һәм промышленность товарлары белән тәэмин итүне яхшырту турында кайгыртучанлыкны көчәйтергә тиешләр. Күп кенә сәүдә оешмаларының эшендә әле зур кимчелекләр бар; потребительгә начар карап фактлары күренә. Профсоюз оешмалары сәүдә челтәренә, продуктларны һәм промышленность товарларын бүлүгә контрольне йомшарттылар.

Дәүләт Оборона Комитеты профсоюзларга сәүдә челтәренә контроль алып бару бурычын йөкләде. Бу—зур һәм мактаулы бурыч. Профсоюз оешмалары магазиннардан продуктларны дөрес итеп һәм ким үлчәмичә җибәрүгә, ашханәләрдә ашларны пешерүгә һәм бирүгә, дәүләт бәяләренең бозылмавына, сәүдә челтәренең санитария хәленә ныклы контроль куярга тиешләр. Барлык бозылган үлчәүләрне иң якын араларда тикшереп чыгарга һәм предприятиеләр көче белән төзәттерергә кирәк. Магазиннарда һәм ашханәләрдә прейскурантлар һәм меню карточкалары яңадан кулланыла башларга тиеш. Аларда бирелә торган ашларның үлчәве һәм бәясе тулысынча күрсәтелергә тиеш. Профсоюзлар сәүдә учреждениеләренең чиста булулары өчен кискен төстә көрәшергә тиешләр.

Февраль аенда предприятиеләрдә һәм учреждениеләрдә җәмәгать контрольләре сайлау эшен тәмам итәргә кирәк. Бу постка коллектив арасында авторитетлары булган, нормаларны һәм калькуляцияләрне яхшы белүче, табылган кимчелекләрне тиз төзәтә алырлык, эшкә чын күңелдән бирелгән, булдыклы кешеләрне күтәрергә кирәк.

Аннары иптәш Шверник докладының икенче өлешенә—хәрби хезмәткәрләрнең семьяларына ярдәм күрсәтү мәсьәләсенә күчә. Ул, сугышчыны фронтта чакта үз семьясы турында борчылмавы өчен Совет Хөкүмәтенең барлык чараларны күрүен әйтә. Бу, сугыш вакытында чыккан күп кенә законнарда чагыла. 19 ай эчендә фронтовиклар семьяларына берничә миллиард сум дәүләт пособиясе түләнде. Предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең коллективлары сугышчыларның семьялары турында якыннан кайгыртучанлык күрсәтәләр.

Ләкин кайбер җирләрдә әле хәрби хезмәткәрләрнең хатыннарына һәм балаларына җансыз карап фактлары бар. Сугышчыларның һәм командирларның семьялары турында кайгырту эшендә профсоюзларга зур җаваплылык йөкләнә. Фронтовикларның семья членнарына эшкә урнашуда гына түгел, бәлки тизлек белән квалификация алуда да булышлык итәргә, аларның балаларын ясленәргә һәм бакчаларга урнаштырырга, фронтовиклар семьяларының барысының да индивидуаль түтәл бакчалары өчен җир алуларына ирешергә һәм бу җирләрне эшкәртүдә ярдәм күрсәтергә кирәк.

Совет сугышчыларының семьяларына игътибар бирү һәм алар турында кайгырту Кызыл Армиянең хәрби куәтен ныгытуга булышлык итәчәк. Бу бурыч безнең халкыбызның гомуми максатыннан—Совет җирен гитлерчы бандалардан чистарту максатыннан аерылмый.

Иптәш Шверник доклады буенча фикер алышуларда катнашкан партия һәм профсоюз работниклары сәүдә челтәренә җәмәгать контроле оештыруда һәм хәрби хезмәткәрләрнең семьяларына ярдәм итүдә зур кимчелекләр барлыкны күрсәтеп үттеләр.

Җыелыш иптәш Шверник докладу буенча киң резолюция кабул итте.

Профсоюз активы, гаять зур күтәренкелек белән иптәш Сталинга котлау хаты кабул итте.

(ТАСС).

Совхозларда язгы кыр эшләренә әзерлекне тамырыннан яхшыртырга!

Кимчелекләрне кабатламаска

Совхоз ул эре хуҗалык. Үзенең эше белән турыдан-туры дәүләт каршында җавап бирә. Анда хезмәтне механикалаштыру, аны дөрес оештыру, хезмәттә дисциплина урнаштыру өчен экономик база бар. Безнең республикабызның территориясенә урнашкан совхозларның күбесе узган җәйдә бу мөмкинлекләрдән тулысынча файдалануны оештырмадылар. Алар эшне сугыш шартлары таләп иткәнчә алып бармадылар. Моны совхозларның дәүләт алдындагы йөкләмәләрне үти алмаулары ачык күрсәтте.

Моның сәбәпләрен түбәндәге җитешсезлекләрдән эзләргә кирәк. «Большевик», «Комсомолец» һәм Вахитов исемендәге совхозларда уңыш бик түбән булды. Ит һәм сөтчелек совхозларында тамыразыклар чәчеп үстерүнең әһәмияте аеруча зур. Ләкин бу совхозлар бәрәңге уңышын күтәрүгә игътибар итмәделәр. «Большевик» һәм Вахитов исемендәге совхозларда бәрәңге уңышы гектарга 12—13 центнер гына туры килә. Бу совхозларда тамыразыклар агротехник кагыйдәләр буенча тәрбияләнмәделәр һәм шуңа күрә дә уңыш аз булды.

Совхозларның икенче җитешсезлеге—орлыкчлык участокларны тәрбияләүгә әһәмият бирмәүдә. Узган җәйдә урып-җыюның озакка сузылуы күп кенә ашлыкны югалтуга сәбәп булды. Урып-җыю «Комсомолец» һәм Чирмешән совхозларында 45—50 көнгә тартылды, ә «Большевик» совхозында 80 көнгә кадәр сузылды. Эшнең вакытында башкарылмавы совхоздагы барлык эшләрне дә тоткарлады.

Быел инде үткәндәге кимчелекләрне кабатламау өчен язгы һәм җәйге эшләргә нык фундамент салынырга тиеш. Яхшы сыйфатлы орлык әзерләү, ремонт һәм агротехника чараларын дөрес үткәрү — югары уңышның нигезе. Бу хәл урып-җыюны вакытында үткәрүне, дәүләт йөкләмәләрен тулысынча үтәүне һәм терлекләр өчен дә кышлык азыкның мул булуын тәэмин итәчәк. Совхоз җитәкчеләре бу эшләрне оештыруны үзләренең сугышчан бурычлары икәнен аңларга тиешләр.

ОВЧИННИКОВ.

ҖИҢҮ ЯЗЫН КАРШЫЛАГАНДА

«Красный Октябрь» совхозы (Яңа Чишмә районы)—орлыкчылык совхозы. Аның меңнәрчә гектарга сузылган чәчү мәйданы һәм йөзләрчә атлары, сыерлары, сарыклары һәм дуңгызлары бар. Авыл хуҗалыгы продуктлары җитештереп, илнең, фронтның таләбен үтәү өчен бирелә кирәкле шартлар бар. Совхозның машина-трактор паркында трактор һәм комбайннар да җитәрлек.

Ләкин моңа карамастан, 1941—42 нче елларда совхоз ватаныбыз каршындагы бурычын үти алмады. Совхозның элекке җитәкчеләренең эшкә җавапсыз, гамьсез караулары, эшчеләр арасында хезмәт дисциплинасын ныгытуга игътибар бирмәүләре нәтиҗәсендә, совхоз мул иген уңышы ала алмады. Урып-җыюның да темпы һәм сыйфаты түбән иде. Шуның нәтиҗәсе буларак, совхоз 1942 нче елда да дәүләт йөкләмәләрен үти алмады.

Соңгы айларда безнең коллектив совхозны шушындый хурлыклы хәлдән чыгару, аны ватаныбызның, фронтның таләбен тулысынча үти алырлык хәлгә китерү өчен барлык көчне туплады. Без быел югары иген уңышы яулап алу өчен җитди чаралар күрәбез. Эшне чәчүлек орлык әзерләүдән, авыл хуҗалыгы машиналарын һәм инвентарьларын яхшы сыйфатлы итеп ремонтлаудан, агротехника чараларын тулысынча үткәрүне оештырудан башладык. Чәчүлек өчен кирәкле орлыкның 58 проценты әзер инде.

Совхозның ремонт мастерское әйбәт итеп җиһазландырылды. Ремонт узел методы белән бара. Һәр бригада 3 әр звенодан тора. Бригадаларга һәм звеноларга көндәлек график бирелде. Аның үтәлеше һәр көнне эш ахырында тикшерелә һәм булган кимчелекләрне шул вакытта ук бетерү чаралары күрелә. Ремонтта эшләүчеләр Кызыл Армиянең 25 еллыгына барлык машиналарны да төзек хәлгә китерергә йөкләмә алганнар иде. Ремонтчылар тарафыннан көндәлек графикның үтәлеп баруы 23 нче февральдә ремонтның тәгәлләнүенә ышанычны арттыра.

Агротехника чараларын үткәрү эшенә дә аерым тармаклар буенча җаваплы кешеләр билгеләнде. Кар тоту, тирес чыгару, ашламалар туплау буенча аерым звенолар оештырылды. Ләкин бу өлкәдә агрономның булмавы эштә комачаулык ясый. Эшне тәҗрибәле картлар ярдәме белән генә башкарырга туры килә. Минем совхозда эшли башлавыма 5 ай булды инде. Шул дәвердә Совхозтрестка күп тапкырлар мөрәҗәгать ителде. Ләкин трест безгә агроном җибәрү чарасын күрмәде. Бу мәсьәләдә Совхозтрест безгә ярдәм итәргә тиеш.

К. ВОРОБЬЕВ,

«Красный Октябрь» совхозы директоры.

Тагын да яхшырак эшләрбез

Куйбышев районындагы «Коминтерн» совхозының партия оешмасы эшчеләр арасында масса-аңлату эшләрен оештыру белән системалы рәвештә шөгыльләнә. Биредә һәрбер эш участогына агитаторлар беркетелгән. Алар һәрбер эштә үзләре башлап үрнәк күрсәтәләр.

Алдынгыларның тәҗрибәләрен уртаклашу өчен әледән-әле киңәшмәләр үткәрелә. Ул киңәшмәләрдә терлек караучылар үзләренең уңышлары һәм аңа ирешүнең методлары турында сөйлиләр.

Коллектив «КИМ» совхозы эшчеләре белән ярыша һәм һәрбер эшче үзара ярышалар. Ярыш договорларының үтәлеше 15 көн саен тикшерелә. Аның нәтиҗәсе турында производство киңәшмәләрендә тыңлана.

Сыер һәм бозау караучылар, шулай ук сыер сауучылар өчен техник укулар оештырылды. Бу укуларга 54 кеше йөри. Биредә занятиеләр атнага 2 тапкыр үткәрелә.

Масса-аңлату эшләренә әһәмият бирү, социалистик ярышны киң җәелдерү һәм эшчеләргә практик булышлык итү нәтиҗәсендә, совхозда стахановчылар саны көннән-көн арта бара. Мәсәлән, иптәш Волков, бозауларны үрнәк булырлык тәрбияләп, аларның авырлык үлчәвен арттыруны 122 процентка кадәр үтәп барды. Ул тәрбияләгән бозаулар арасында үлү фактлары бөтенләй булмады. Сыер сауучы иптәш Шинкарева һәрбер фуражный сыердан 1.679 литр сөт савып алуга ирешә.

Коллективның бердәм энергия белән эшләве нәтиҗәсендә, терлекләрне кышлатуга тулы әзерлек тәэмин ителде. Терлек азыклары җитәрлек әзерләнде.

Ләкин шуны әйтергә кирәк, совхозда дәүләт йөкләмәләренең кайбер төрләренең шушы көнгә кадәр үтәлеп җитмәве безнең эштә төп җитешсезлек булып тора. Без бу җитешсезлекләрне иң кыска вакыт эчендә бетерербез. Ватаныбыз, Кызыл Армиябез өчен тагын да яхшырык эшләрбез.

А. КАЛУГИН,

«Коминтерн» совхозы директоры.

КИҢӘШМӘДӘ

2 нче һәм 3 нче февральдә Татарстан совхозлары директорларының, политбүлек начальникларының, агрономнар һәм зоотехниклар белән берлектә республика киңәшмәсе булды. Киңәшмәдә язгы эшләргә әзерлекнең барышы һәм терлекләрне кышлатуның торышы турында доклад белән совхозтрест директоры иптәш Дубей чыкты.

Доклад буенча фикер алышуларда күп кенә иптәшләр катнаштылар. Алар аерым совхозларда булган җитди кимчелекләрне кискен тәнкыйтьләделәр. Киләчәктә эшне яхшырту өчен эшлекле тәкъдимнәр бирделәр. Киңәшмә совхозларда хезмәтне дөрес оештыру, терлекчелекне тагын да үстерү, 1943 нче елда югары иген уңышы яулап алуга фундамент әзерләү буенча конкрет чаралар билгеләде.

Киңәшмә совхозтрест аппаратында моңа кадәр булган кимчелекләрне күрсәтте һәм аның совхозларга практик рәвештә оператив җитәкчелек итүен таләп итте.

ТЕЛЬМАН ИСЕМЕНДӘГЕ СОВХОЗДА

Алексеевский районында Тельман исемендәге совхоз зоотехнигы иптәш Монахов эшне зоотехника нигезендә оештыру өчен бөтен көчен бирә. Совхоз эшчеләренә якыннан торып булыша. Узган ел сыерлардан 304 бозау алынган иде. Хәзер аларның 294 е исән-сау үсәләр. Бозаулар караучы иптәш Коршинина иң яхшы эшчеләрнең берсе. Ул тәрбияли торган бозаулар барысы да көр һәм таза үсәләр.

Бу совхозда атларны карау да яхшы. Аларга тупас азыклар парлап, эшкәртеп ашатылалар. Терлекләр белән мөгамәлә яхшы булганга күрә дә, совхоз терлекчелек буенча дәүләт йөкләмәләрен вакытында үтәп килә. Сөт тапшыру буенча совхоз—республикада алдынгыларның берсе. Ит тапшыруны тулысынча тәгәлләп, 1943 нче ел өчен дә 251 центнер тапшырды инде.

Н. МАГСУМОВА.

СОВХОЗ СТАХАНОВЧЫСЫ

— Бозаулар барысы да исән үсәләрме?—дип сорау биргәч, «Коминтерн» совхозының бозау караучысы Иван Тимофеевич гаҗәпләнеп башын селкеп куйды.

— Мондый сорау урынсыз. Минем кулга эләккән бозаулар барысы да исән үсәләр. Сез, бозауларның авырлык үлчәве ничек арта? дип сорагыз. Бозау тәрбияләүнең сыйфатын менә шул билгели.

— Январь ае—кышның иң салкын вакыты. Бу айда яшь терлекләрне тук тотарга, салкыннан сакларга кирәк. Шулай да, мин карый торган бозауларның авырлыгы январь аенда да нормаль артты,—дип куйды да, яшь терлекләр тәрбияләү буенча үзенең җәйге һәм кышкы тәҗрибәләре турында сөйли башлады.

Иван Тимофеевичның бу эштә тәҗрибәсе күп. Ул 5 ел Соколка совхозында эшләде. Менә 6 нчы ел инде «Коминтерн» совхозында шул ук эшне башкара. Ул бозауларны ике төркемгә бүлеп тәрбияли. Үгез бозауларны таза итеп үстереп, дәүләткә симез ит тапшыру өчен тырыша. Тана бозаулардан инде нәселле көр сыерлар җитештерүне күздә тота. Ит товарлыгы өчен тәрбияләнә торган бозауларны кабул итү пунктына кадәр үзе озата.

— Мин аларны үзем симерттем, көрлекләрен киметмәү өчен юлда барганда да ашыкмыйча, вакытында ашатып, эчертеп, ял иттереп алып барам. Бозауларның авырлык үлчәве кимеми,—ди.

Совхозда бозауларның көнлек рационы 6 килограмм печәннән, 2 килограмм силостан, бер килограмм солы онынннан һәм берникадәр тоздан тора. Иван Тимофеевич бу азыкларны дүрткә бүлеп ашата. Иртәнге азыкның күләме көндезге һәм кичкегә караганда артыграк була. Бозаулар үзләренә бирелгән азыкны ашап бетерүгә җылымса су әзерләнә. Парланган һәм солы оны белән болгатылган туклыклы азыкны ашаганнан соң, бозаулар җылы суны рәхәтләнеп эчәләр. Көндезге ашау алдыннан алар саф һавага чыгарылалар. Бу вакытта да бозаулар караучысыз калмыйлар. Аларны Иван Тимофеевичның булышчылары Сидорова һәм Волкова иптәшләр карап йөртәләр.

Кичкә таба инде бозаулар торагы чистартыла. Аларның асларына җәелгән саламнар коры салам белән алмаштырыла. Кичке азыкны ашап, су эчкәннән соң бозаулар коры урынга ятып рәхәтләнеп күшикүши йокыга китәләр.

Вакытлы ашату, бозауларның тору урыннарын чиста һәм җылы тоту аркасында совхозның терлекләре бик нормаль арталар, көр булалар. Җәйге сезонда да Иван Тимофеевич көтүне үзе йөртә.

— Терлекләрне яратып ашый торган үләнле урыннарда йөртәм мин. Сазлык урыннарга кертмим. Минем бозауларым көтүдә уйный-уйный йөриләр,—ди ул.

Совхоз быел ит йөкләмәсе өчен 35 көр бозау симертеп бирде. Көр таналар үстерү совхоздагы сыерларның санын 50 гә арттырды. Иван Тимофеевич тагын 102 бозау тәрбияләп үстерә.

— Героик Кызыл Армиябезгә симез-симез бозаулар үстерүне, совхозга нәселле таналар тәрбияләүне үземнең төп бурычым дип аңлыйм,—ди.

Менә, совхоз стахановчысы, эшчән карт иптәш Волковның хезмәте шундый.

М. НУРЕТДИНОВА.

ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. Рәсемдә: Н-че частьның суыгшчылары халык яши торган пунктта дошманга каршы сугышлар.

ТАСС фотохроникасы.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

6 нчы ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

6 нчы февральдә Украинада безнең гаскәрләр бик каты сугышлар нәтиҗәсендә **Лисичанск** шәһәрен һәм тимер юл станциясен, **Барвенково** шәһәрен һәм тимер юл станциясен, **Балаклея** шәһәрен һәм тимер юл станциясен алдылар.

Ростов-Доннан көньяктарак безнең гаскәрләр каты сугыштан соң **Батайск** шәһәрен һәм тимер юл узелын һәм халык яши торган зур пунктлардан **Койсугны** алдылар.

Безнең газсәкрләр, һөҗүмне уңышлы җәелдерүне дәвам иттереп Азов диңгезе ярына чыктылар һәм **Ейск** шәһәрен һәм портын алдылар. Ейскидан көньяктарак һәм көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр район үзәге **Ново-Минскаяны,** халык яши торган зур пунктлардан **Ясенканы, Копанскаяны, Привольнаяны, Чепегинскаяны, Переяславскаяны** алдылар.

Старый Осколдан көнбатыштарак һәм көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр район үзәкләреннән **Больше-Троицкоены, Велико-Михайловканы, Мантуровоны** алдылар.

Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып баруны дәвам иттерделәр.

* * *

5 нче февральдә безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның 8 танкысын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 200 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 6 артиллерия батареясының утын бастырдылар, 6 сугыш припаслары складын шартлаттылар һәм бер батальонга якын дошман пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Ростов-Доннан көньяктарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүм алып бардылар һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бик күп трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды. Халык яши торган бер пункт районында Н-че часть сугышчылары немецларның 2 ротага якын пехотасын юк иттеләр һәм 19 орудие, 33 пулемет, төрле йөкләр төялгән 112 автомашина, 72 мотоцикл, сугыш припаслыр һәм азык тутырылган 7 склад кулга төшерделәр.

* * *

Н-че берләшмә частьлары, Изюм шәһәрен һәм тимер юл станциясен алганнан соң, һөҗүмне җәелдерделәр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Бер пункт районында безнең сугышчылар немецларның үзләренең җимерелгән частьларына ашыгыч рәвештә ярдәмгә җибәргән бер полк пехотасын тар-мар иттеләр. 5 танк, шул исәптән 4 авыр танк, 7 орудие, бер самоход пушка һәм 48 автомашина кулга төшерелде.

* * *

Купянскидан көнбатыштарак Н-че гвардия берләшмәсе частьлары дошман танкларына һәм пехотасына каршы каты сугышларда гитлерчыларны халык яши торган берничә пункттан бәреп чыгардылар. 4 танк, 2 бронемашина зарарланды һәм яндырылды, дошман гаскәрләре төялгән 35 автомашина юк ителде. Бер участокта немецлар контратака ясап карадылар, ләкин, сугыш кырында үз солдатларының һәм офицерларының 300 дән артык гәүдәләрен калдырып, алып ташландылар.

* * *

Курскидан көнчыгыштарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган күп пунктларны немец-фашист басып алучылардан азат иттеләр. Н-че часть сугышчылары немецларның 3 танкысын, 27 орудиесен, 13 минометын, 42 пулеметын, сугыш милекләре тутырылган 3 складын һәм башка трофейлар кулга төшерделәр. Бер авыл районында немецлар күп кенә ДЗОТ лар һәм танкка каршы киртәләр ясаганнар. Безнең танкистлар, авыл юллары буйлап барып, бу авылны әйләнеп үттеләр һәм шуннан соң көнбатыштан гитлерчыларга каршы атака ясадылар. 200 дән артык немец солдатлары һәм офицерлары, дошманның танкка каршы ата торган 11 орудиесе юк ителде. Пленныйлар алынды.

* * *

Смоленск өлкәсендә хәрәкәт итүче, «Смерть фашизму» исемле отрядның партизаннары, немецларның кавалерия полкы үтеп бара торган юлда засада оештырганнар. Совет патриотлары немецларның якынрак килүләрен көтеп торып, аларга каршы мылтык һәм пулемет уты ачканнар. Дистәләрчә гитлерчылар үтерелгән, ә калганнары кире киткәннәр. Шул арада пулеметчы партизаннар, аркылы ут ярдәме белән, чигенеп баручы немецларга каршы ташланганнар. Юлда 100 дән артык үтерелгән немец солдатлары һәм офицерлары калган.

* * *

Житомирдагы немецлар полициясе начальнигы подполковник Эмлер үткән елның 18 нче декабрендә немецларның 586 нчы пехота полкы командиры Вальтер Даммашка болай дип язган: «...Берничә көн инде мин Украинада. Монда тревогалы җанлылык. Партизаннар һәркөнне диярлек әле анда, әле монда килеп чыгалар. Без аларга каршы шактый көчле сугышлар алып барабыз һәм бик зур югалтуларга дучар ителдек инде. Кичә генә мин бер районда сугыш алып барган ротадан 6 офицерны һәм 50 ләп солдатны югалттым...».

* * *

Түбәндә Воронеж өлкәсенең Екатериновка авылында немец-венгер кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «Немецлар һәм венгерлар безнең авылны алгач ук совет гражданнары өчен хокуксыз һәм шатлыксыз тормыш башланды. Бандитлар бөтен халыкны таладылар һәм йортларыннан куып чыгардылар. Һәрбер кеше җиңендә номер язылган тасма йөртергә тиеш булды. Такмаган кешеләр үлем җәзасы белән куркытылдылар. Оккупантлар барлык ирләрне һәм хатын-кызларны тәүлегенә 16 шар—18 әр сәгать буена юл чистардуда эшләргә мәҗбүр иттеләр. Эшкә чыкмаган өчен үлем җәзасы бирелде. Аз гына соңга калсаң да камчылар белән суктырдылар. Фашистлар безнең 420 бала укый торган мәктәпне туздырдылар. Укытучы хатын-кызларны алар солдат кухнясында эшләргә, су ташырга, савытлар юарга һәм солдат керләре уарга мәҗбүр иттеләр. Немец ерткычлар укытучы Екатерина Комгорованы газапладылар һәм үтерделәр, Анастасия Пилипенконы, Евдокия Прорешнаяны, Николай Прохоровны, Андрей Голосковны һәм авылның башка кешеләрен аттылар». Актка авыл советы председателе З. Прокофьев, колхозчылардан Е. Ковалева, С. Прохоров, С. Прорешный, Е. Олемская, укытучылардан Н. Попова, М. Красовская, Р. Якозлева һәм авылның башка кешеләре кул куйды.

РУС АРМИЯСЕНЕҢ БАТЫРЛЫГЫ ТУРЫНДАГЫ ДАН МӘҢГЕ ЯШӘР

СТАЛИНГРАД ЯНЫНДА НЕМЕЦЛАРНЫ ТАР-МАР ИТҮ ТУРЫНДА ЧИТ ИЛ МАТБУГАТЫ

АМЕРИКА

НЬЮ-ЙОРК, 5 февраль. (ТАСС). Хәзер Америка газеталарында иң күренерлек урынны Кызыл Армиянең Сталинград янындагы җиңүе турындагы хәбәрләр алып тора. Бу вакыйгага газеталар зур мәкаләләр багышлыйлар һәм Кызыл Армия тарафыннан плен алынган Германия генералларын күрсәтә торган рәсемнәрне урнаштыралар.

«Нью-Йорк геральд трибюн» газетасының хәрби күзәтчесе майор Элиот болай дип яза: «Немец басып алучыларның планнары Сталинград янында тузанга әйләнде. Сталинград янындагы тар-мар ителү Гитлерның һәм аның армиясенең, әлбәттә, һәлак булачагын искә төшерә. Совет гаскәрләренең җиңүе—аларның батырлыгының һәм верховный командованиенең зирәклегенең нәтиҗәсе. Бу сугышта руслар күрсәткән осталыкка бәя биреп бетерү мөмкин түгел. Рус армиясенең бу батырлыгы гасырлар буена истә калыр. Азатлык өчен үләргә хәзер торучы азат кешеләр исән булганда ул беркайчан да онытылмас».

«Нью-Йорк таймс» газетасы болай ди: «Сталинград янындагы сугыш хәзерге замандагы барлык сугышларның иң катысы булды. Ихтимал, хәл иткеч сугыш та булыр. Сталинград янында Германия һәм Россия гаскәрләре үзләренең түземлелекләре һәм батырлыклары ни дәрәҗәдә икәнлекне күрсәттеләр.

АНГЛИЯ

ЛОНДОН, 5 февраль (ТАСС). Рейтер агентлыгы Англиянең мәгълүм журналисты Уикхэм Стидның Сталинград янында Кызыл Армиянең җиңүенә багышланган күзәтүен тапшыра. Стид болай дип яза: «Моннан 90 ел элек Англиядә «Бөтен дөнья күләмендә булган хәлиткеч 15 сугыш» дигән китап чыккан иде. Бу китапта борынгы греклардан алып яңа заманга кадәр булган иң зур сугышлар саналган. Иң күренекле урынга Полтава янында Петр Великий командалыгындагы рус гаскәрләренең Швеция армиясен тар-мар итүләре куелган иде. Киләчәктәге тарихчылар Сталинград өчен барган сугышны нинди урынга куярлар икән? Бу бөек сыналышның берничди дә тиңдәше юк һәм ул гадәттән тыш истә калырлык нәтиҗәләргә китерәчәк. 330 мең кешедән торган, хәзерге заманның барлык сугыш средстволары белән тулысынча коралланган һәм гаять зур складлары һәм транспорты булган, һөҗүм итеп килгән армиянең моның кебек чолганып алынуы һәм бөтенләй юк ителүе әле тарихта булганы юк иде. Германия армиясенең җиңелмәслеге турындагы әкият бетте. Гитлерның хәрби җитәкчелегенең дәрәҗәсе төште, аның үз дәрәҗәсенә дә җимергеч удар ясалды. Тарихчылар Сталинград янында булган сугышны Европаның һәм, ихтимал, бөтен дөньяның да язмышында борылыш пункты дип карый алырлар. Сталинград өчен булган сугышта русларның җиңүе хәзерге сугышның яңа фазасы, ихтимал, хәл иткеч фазасы булыр. Черчилльнең Касабланкада Рузвельт белән очрашканнан соң Төркиягә һәм Кипр атавына баруы бу фазаның тиздән башланырга тиешлеген күрсәтә. Бу фаза союзниклар гаскәрләренең Европага басып керүләреннән гыйбарәт булачак.

КАНАДА

ОТТАВА, 5 февраль. (ТАСС). Канада матбугаты Кызыл Армиянең Сталинград янындагы җиңүе турында шатлыклы хәбәрләр урнаштыра. Баш мәкаләләр һәм күзәтүләр немец фашист гаскәрләренә каршы көрәштә Кызыл Армия ирешкән уңышларга багышлана. Торонтода чыга торган «Стар» газетасының хәрби күзәтчесе Плюмен болай дип яза: «Сталинград янында Германия гаскәрләренең тар-мар ителүе Германиянең тәмам җимерелүен якынайта. Сталинград янында булган сугыш Советлар Союзының кораллы көчләренең куәтен һәм аларның җитәкчеләренең осталыгын күрсәтте».

«Глоб энд мейл» газетасы күзәтчесе Рид, Гитлерның властьны тартып алуының 10 еллыгы, Кызыл Армиянең Германия гаскәрләрен җиңүләре нәтиҗәсендә, соңгы еллык булыр, дип яза.

Ассошиэйтед Пресс агентлыгы күзәтчесе Блейколи болай ди: «Сталинград янында булган сугыш—Гитлер Германиясе өчен һәлакәт. Бу сугышта иң бөек стратег һәм полководец Сталинның җитәкчелеге отып чыкты. Германиянең гаять зур көчләрен тиңдәшсез рәвештә тар-мар итүне Сталин оештырды».

Союзниклар авиациясенең Туринга, Специягә, Рурга һәм Лорианга һөҗүме

ЛОНДОН, 5 февраль. (ТАСС). Рәсми рәвештә хәбәр ителүенчә, кичә Америка бомбардировщиклары сугыш башланганнан бирле икенче тапкыр көндез төньяк-көнбатыш Германиядәге күп кенә объектларга һөҗүм иткәннәр. Бомбардировщикларның хәрәкәтенә дошман истребительләренең зур булмаган берләшмәсе каршылык күрсәткән.

ЛОНДОН, 5 февраль. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, 5 нче февральгә каршы төндә, Англия самолетлары Италиянең автомобиль промышленносте үзәге Туринны һәм диңгез базасы Специяне көчле рәвештә бомбага тотканнар. Шуның белән бер үк вакытта бомбардировщикларның икенче берләшмәсе Рурга һәм Франциянең Атлантика ярыбуенда Германиянең төп су асты көймәләре базасы булган Лорианга атака ясаганнар.

Лорианга ясалган соңгы көчле һөҗүмнең нәтиҗәләре әлегә билгеле түгел. Моннан элек ясалган һөҗүмнәр вакытында портка һәм ремонт мастерскойларына, коюу цехларына, складларга һәм электр станцияләренә җитди зарар китерелгән. Диңгез казармалары, офицерлар клубы һәм Германия комендатурасы бидалары җимертелгән. Газ саклау урынына һәм күп кенә заводларга бомбаларның туры төшкәнлеге күренгән. Бары тик бер хәрби диңгез арсеналында гына да 10 акр мәйданда җимерелүләр булганлыгы төшереп алынган.

Туринда, аэрофоторәсемнәр мәгълүматлары буенча 70 промышленность предприятиеләре, шул исәптән барлык эре хәрби заводлар шактый дәрәҗәдә зарарланганнар.

Җаваплы редактор урынбасары
ГАЛИМ РЯБКОВ.

Театрларда һәм киноларда

Татар дәүләт опера һәм балет театры. Бүген—„*Ильдар*". 8 нче февральдә—„*Чио-Чио-Сан*".

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. 7 нче февральдә—„*Хуҗа Насретдин*".

Зур драма театры. Бүген көндез һәм кич — „*Фельдмаршал Кутузов*". 8 нче февральдә — „*Маскарад*". Бөтен җыелган акча оборона фондына биреләчәк. Спектакльдән соң танецлар.

Яшь тамашачылар театры. Бүген—12 сәгать 30 минутта, кичке 4 сәгатьтә һәм 8 сәгатьтә „*Скосыревлар семьясы*" („Фронт").

Татар дәүләт филармониясе Менжинский исемендәге клубта 8 нче февральдә миниатюра һәм *концерт кичәсе*. Кич 8 сәгатьтә башлана. Билетлар сатыла.

Дәүләт циркы. Бүген көндезге 1 сәгатьтә, кичке 6 һәм 9 сәгатьтә еч тамаша һәм французча көрәш ярышлары.

„Электро" — музыкаль комедия „*Антоша Рыбкин*".

„Унион"—„*Котовский*".

„Пионер" көндез һәм кич — *3 нче номерлы кино-сборник*.

„Чаткы"—„*Өч мушкетер*".

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—АТС 73—27, редактор урынбасары—АТС 76—29. секретарь—АТС 79—29. Партия тормышы бүлеге 14—75, промышленность-транспорт һәм хатлар бүлеге АТС 75—55, авыл хуҗалыгы бүлеге АТС 76—14, типография 36—60.

ПФ 635 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГАРФ ИЯСЕ № Заказ 213